РУКОВОДИТЕЛЬ
ИСПОЛНИТЕЛЬНОГО КОМИТЕТА
САРМАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
САРМАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
ҖИТӘКЧЕСЕ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

12.05.2021 с. Сарманово № 155

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
административ комиссиясен төзү турында

«Муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына административ комиссияләр эшчәнлеген булдыру һәм оештыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2005 елның 30 декабрендәге 144-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы һәм «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының административ комиссиясен төзү турында» 2021 елның 19 апрелендәге 30 номерлы карары нигезендә Сарман муниципаль районы башкарма комитеты карар бирә:

1. Сарман муниципаль районының административ комиссиясен төзергә.

2. Расларга:

Сарман муниципаль районының административ комиссиясе составын (1 нче кушымта);

Сарман муниципаль районы административ комиссиясенең эш регламентын (2 нче кушымта).

3.Сарман муниципаль районы административ комиссиясенең вәкаләтләре срогы әлеге административ комиссиянең беренче утырышыннан башлана һәм биш ел тәшкил итә.

4. Сарман муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы административ комиссиясе турында» 2012 елның 10 октябрендәге 371 нче карары (25.11.2013 ел, № 470; 30.01.2015 ел, № 32; 11.09.2015 ел, № 527; 28.09.2018 ел, № 386; 11.12.2019 ел, № 334; 15.04.202020 ел, № 118 үзгәрешләр белән), Башкарма комитет җитәкчесенең «Сарман муниципаль районы административ комиссиясе эше регламентын раслау турында» 2010 елның 26 августындагы 336 нчы карары үз көчен югалткан дип санарга.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (https://pravo.tatarstan.ru/) бастырып чыгарырга һәм Сарман муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Башкарма комитет җитәкчесе Ф. А. Вәлиев

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Башкарма комитетының
«12» 05 2021елның
155 номерлы карарына
1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы
административ комиссиясе составы

| | |
|---|---|
| Комиссия рәисе: | |
| Вәлиев<br>Фәндәс Әнәс улы | Сарман муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе |
| Рәис урынбасары: | |
| Сафин<br>Наил Әнвәр улы | Сарман муниципаль районы Башкарма комитеты эшләре идарәчесе |
| Комиссия секретаре: | |
| Фәртдинова<br>Алинә Марат кызы | Сарман муниципаль районы Башкарма комитетының административ комиссиясе баш белгече |
| Комиссия әгъзалары: | |
| Сахуриев<br>Николай Иванович | Сарман муниципаль районы Сарман авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе |
| Галләмов<br>Илшат Фикс улы | Сарман муниципаль районы Җәлил ш. т. п. Башкарма комитеты җитәкчесе |
| Әбрарова<br>Диләрә Фоат кызы | Сарман муниципаль районы Җәлил ш. т. п. Советының оештыру эшләре буенча бүлеге баш белгече |
| Латыйпов<br>Илшат Ирек улы | Полиция участогы уполномоченныйлары һәм ПДН бүлеге начальнигы (килешү буенча) |

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Башкарма комитетының
«12» 05.2021 елның 135 номерлы
карарына
2 нче кушымта

**Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы административ комиссиясе эше
регламенты**

Әлеге регламент Сарман муниципаль районы административ комиссиясенең (алга таба – административ комиссия) эш тәртибен билгели.

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Административ комиссия әлеге эш регламентын раслаучы Сарман муниципаль районының башкарма комитеты тарафыннан төзелде.

1.2. Административ комиссия Россия Федерациясе Конституциясе һәм Татарстан Республикасы Конституциясе, Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексы, Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексы, «Муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына административ комиссияләр төзү һәм аларның эшчәнлеген оештыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2005 елның 30 декабрендәге 144-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба – Татарстан Республикасы Законы) һәм Сарман муниципаль районы җирле үзидарә органнарының муниципаль хокукый актлары нигезендә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыра.

1.3. Административ комиссия Татарстан Республикасы Административ хокук бозулар турында кодексында каралган административ хокук бозулар турындагы эшләрне карау өчен төзелә торган даими эшләүче коллегиаль орган булып тора һәм Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы чикләре эчендә эшли.

1.4. Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексы һәм Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексы нигезендә һәр эшне һәрьяклап, тулы, объектив һәм вакытында карау, чыгарылган карарның үтәлеше, шулай ук административ хокук бозуларны кисәтү административ комиссиянең бурычлары булып тора.

1.5. Административ комиссия вәкаләтләре срогы административ комиссиянең беренче утырышыннан башлана һәм биш ел тәшкил итә.

1.6. Административ комиссия әгъзасы вәкаләтләре Татарстан Республикасы Законында каралган очракларда вакытыннан алда туктатыла.

1.7. Сарман муниципаль районы башкарма комитеты административ комиссиянең үз вәкаләтләрен вакытыннан алда туктаткан әгъзасы урынына административ комиссиянең яңа әгъзасын, административ комиссия әгъзасының вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату турында карар кабул ителгән көннән алып бер айдан да соңга калмыйча, билгеләргә тиеш.

1.8. Административ комиссиядә административ комиссиянең тулы исеме булган мөһере бар.

## 2. Административ комиссия эшен оештыру

2.1. Административ комиссия Сарман муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан билгеләнгән рәисеннән, рәис урынбасарыннан, административ комиссиянең җаваплы секретареннән һәм административ комиссия әгъзаларыннан (алга таба – административ комиссия әгъзалары) тора.

2.2. Административ комиссия әгъзалары үз вәкаләтләрен Татарстан Республикасы Законы нигезендә гамәлгә ашыралар.

2.3. Административ комиссиянең персональ һәм санлы составы Сарман муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе тарафыннан кимендә 5 әгъза билгеләнә һәм так санда булырга тиеш.

2.4. Даими штат нигезендә административ комиссия составына административ комиссиянең җаваплы секретаре керә. Административ комиссиянең башка әгъзалары, әлеге Регламентның 2.5 пунктында каралган очраклардан тыш, иҗтимагый башлангычларда административ комиссиядә эшлиләр.

2.5. Сарман муниципаль районы Башкарма комитеты карары буенча административ комиссиянең башка әгъзалары үз вазыйфаларын даими түләнә торган нигездә җирле бюджет акчалары хисабына башкара алалар.

2.6. Административ комиссия рәисе рәис урынбасары һәм административ комиссиянең җаваплы секретаре арасында вазыйфаларны бүлә, аларның функцияләрен Татарстан Республикасы Законы белән бирелгән вәкаләтләр чикләрендә билгели.

2.7. Административ комиссия рәисе административ комиссия әгъзаларының, шулай ук административ комиссия рәисе урынбасарының һәм җаваплы секретаренең квалификациясен күтәрү эшен оештыра.

2.8. Административ комиссия мөрәҗәгать итүчеләрне кабул итә ала. Мөрәҗәгать итүчеләрне кабул итү тәртибе административ комиссия рәисе күрсәтмәсе белән билгеләнә.

2.9. Административ комиссия адресына гражданнардан һәм юридик затлардан кергән шикаятьләр һәм мөрәҗәгатьләр гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда карала.

2.10. Административ хокук бозулар буенча эшләр административ комиссиядә саклана һәм 3 ел узгач, Сарман муниципаль районы башкарма комитеты архив бүлегенә тапшырыла.

## 3. Административ комиссия утырышын чакыру һәм уздыру тәртибе

3.1. Административ хокук бозулар турындагы эшләрне карау административ комиссия тарафыннан Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексында билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

3.2. Административ хокук бозулар турындагы эшләр административ комиссия утырышларында карала. Административ комиссия утырышын уздыру датасы, вакыты һәм урыны турындагы карар аның рәисе тарафыннан, ә ул булмаганда - рәис урынбасары тарафыннан, административ хокук бозулар турында беркетмәләр һәм башка материаллар кергән саен, аена кимендә 2 тапкыр кабул ителә.

3.3. Административ комиссия утырышлары административ хокук бозулар турындагы эшләрне карау срокларын үтәүне тәэмин итә торган вакыт аралыгы белән уздырыла.

3.4. Административ комиссиянең җаваплы секретаре административ комиссия әгъзаларына административ комиссия утырышын үткәрү датасы, вакыты һәм урыны турында административ комиссия утырышына кадәр кимендә 2 көн алдан хәбәр итә.

3.5. Административ комиссия утырышында катнашу мөмкин булмаган очракта, рәис, рәис урынбасары һәм комиссия әгъзалары бу хакта административ комиссиянең җаваплы секретаренә, кагыйдә буларак, административ комиссия утырышына кадәр ике эш көнгә алдан хәбәр итәргә тиеш.

3.6. Административ комиссия утырышы, әгәр анда административ комиссия әгъзаларының билгеләнгән саныннан кимендә өчтән икесе катнашса, хокуклы булып санала.

3.7. Административ хокук бозу турындагы эше буенча карар, билгеләмә утырышта катнашучы административ комиссия әгъзаларының гади күпчелек тавышы белән кабул ителә.

## 4. Административ җәза бирү турындагы карарны үтәү.

4.1. Административ комиссия тарафыннан чыгарылган карарлар Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексы нигезендә үтәлә.

4.2. Эштә катнашучы затларның, башка физик һәм юридик затларның административ комиссия тарафыннан чыгарылган карарларын, билгеләмәләрен һәм тәкъдимнәрен контрольдә тотуны административ комиссиянең җаваплы секретаре гамәлгә ашыра.

## 5. Административ хокук бозуларны профилактикалау.

5.1. Административ хокук бозуларны кисәтү максатларында административ комиссия эчке эшләр органнары, Суд приставлары федераль хезмәте идарәсенең территориаль бүлекләре, Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы, башка органнар һәм иҗтимагый берләшмәләр белән үз эшчәнлеген координацияли.

5.2. Административ комиссия күчмә утырышлар, шул исәптән муниципаль район җирлегендә, рәис раслаган график буенча уздыра.

5.3. Административ комиссия үз эшчәнлеген массакүләм мәгълүмат чараларында яктырту һәм халык арасында аңлату эшләре уздыру юлы белән профилактик эш оештыра.